СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

17.12.2019 Алабуга шәһәре № 432

«2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы муниципаль
берәмлегенең бюджеты турында»

Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы, Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмә нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1 **нче статья**

1. 2020 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга (алга таба район бюджеты):

1) район бюджеты керемнәренең фаразланган гомуми керем күләме - 1 712 751,8 мең сум күләмендә;

2) район бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен -1 712 751,8 мең сум күләмендә;

3) район бюджеты дефициты - 0 мең сум күләмендә.

2. 2021 елга һәм 2022 елга район бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) 2021 елга район бюджеты керемнәренең фаразланган гомуми күләме - 1 724 525,1 мең сум һәм 2022 елга - 1 737 530,4 мең сум күләмендә;

2) 2021 елга район бюджеты чыгымнарының гомуми күләме - 1 724 525,1 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы расланган чыгымнар - 22 088,2 мең сум, 2022 елга- 1 737 530,4 мең сум күләмендә, шул исәптән расланган шартлы чыгымнар - 46 152,7 мең сум күләмендә;

3) 2021 елга район бюджетының дефициты - 0 мең сум, 2022 елга - 0 мең сум күләмендә.

3. 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын, әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 нче статья**

1. 2021 елның 1 гыйнварына түбәндәгеләрне расларга:

1) Алабуга муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә билгеләргә, шул исәптән Россия Федерациясе валютасында Алабуга муниципаль районы арантияләр буенча 0 мең сум күләмендә билгеләргә;

2. 2023 елның 1 гыйнварына торышы буенча түбәндәгеләрне расларга:

1) Алабуга муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә билгеләргә, шул исәптән Россия Федерациясе валютасында Алабуга муниципаль районы арантияләр буенча 0 мең сум күләмендә билгеләргә;

**3 нче статья**

Район бюджетында, әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә, 2020 елга һәм 2021 һәм 2021 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы бюджетының фаразланучы керемнәре күләмен исәпкә алырга;

**4 нче статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 601 статьясындагы 2 пункты нигезендә, 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

**5 нче статья**

2020-2022 елларда Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетына 2019 ел йомгаклары буенча салымнарны түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң калган Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре табышының бер өлешен кертү 2020 елның 1 июленә кадәр чиста табышның 30 проценты күләмендә башкарыла дип билгеләргә.

**6 нчы статья**

1. Район бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

**7 нче статья**

1. 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына район бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетының 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары (Алабуга муниципаль районының муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), һәм төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Алабуга муниципаль районының максатчан статьялары (дәүләт һәм муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программасыз юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, 2020 елга һәм 2021, 2021 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә бүлүне расларга.
4. 2020 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 67 439,7 мең сум, 2021 елга 68 932,1 мең сум һәм 2022 елга 70 484,1 мең сум күләмендә расларга.

**8 нче статья**

Район Советы карары белән район бюджеты турында каралган товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм физик затларга субсидияләр Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә бирелә.

**9 нчы статья**

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә бүлү белән расларга:
1) 2020 елга 36 908,3 мең сум күләмендә;
2) 2021 елга 33 319,9 мең сум күләмендә;

3) 2022 елга 35 266,0 мең сум күләмендә.

**10 нчы статья**

Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Танай авыл җирлеге бюджетына субвенцияләр күләмен:
2020 елга -5,0 мең сум күләмендә расларга;
2021 елга -5,0 мең сум күләмендә;
2022 елга -5,0 мең сум күләмендә.

**11 нче статья**

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр күләмен әлеге карарның 10 нчы кушымта нигезендә расларга:

1) 2020 елга -1519,3 мең сум күләмендә;
2) 2021 елга -1521,5 мең сум күләмендә;
3) 2022 елга -1545,3 мең сум күләмендә.

12 **нче статья**

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен район бюджетына Алабуга шәһәр җирлеге бюджетыннан район бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар күләмен исәпкә алырга:

1) торак-коммуналь хуҗалык буенча төзелгән килешүләр нигезендә 2020 елга - 32 120,0 мең сум; 2021 елга -32 120,0 мең сум һәм 2022 елга -32 120,0 мең сум күләмендә;

2) мәдәният буенча 2020 елга - 91 082,6 мең сум, 2021 елга - 91 530,4 мең сум һәм 2022 елга - 94 507,6 мең сум күләмендә.

**13 нче статья**

Район бюджетында муниципаль учреждениеләрне тоту буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә җирлекләр бюджетларыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган бюджетара трансфертларны, әлеге карарның 11 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга:

1) 2020 елга 2 850,0 мең сум күләмендә;
2) 2021 елга 2 900,0 мең сум күләмендә;
3) 2022 елга 3 000,0 мең сум күләмендә.

**14 нче статья**

Алабуга муниципаль районының муниципаль юл фонды ассигнованиеләре күләмен:
2020 елга - 25 100,0 мең сум күләмендә,
2021 елга - 27 900,0 мең сум күләмендә,
2022 елга - 29 400,0 мең сум күләмендә расларга һәм аларны 2020, 2021 һәм 2022 елларга Алабуга муниципаль районының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә.

**15 нче статья**

Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган, Татарстан Республикасы Законнарында һәм башка норматив-хокукый актларында, шулай ук Алабуга муниципаль районының норматив-хокукый актларында каралган очраклардан тыш, 2020 елда карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.
2. Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарына 2020 елда муниципаль хезмәткәрләр санын арттыруга китерә торган карарларны кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

**16 нчы статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык органнарының район бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара, шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә район бюджетын үтәү буенча аерым функцияләр башкара.

**17 нче статья**

Товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Алабуга муниципаль районы исеменнән төзелгән дәүләт контрактлары буенча

түләү өчен бирелеп, әлеге дәүләт контрактлары шартлары нигезендә 2019 елда түләнергә тиешле файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә район бюджетының 2020 елның 1 гыйнварына калган акчалары 2020 елда, Татарстан республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелә.

**18 нче статья**

Суд эшчәнлеге турындагы, башкару эшчәнлеге турындагы һәм бөлгенлек (банкротлык) турындагы россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда Алабуга муниципаль районының финанс-бюджет палатасы Россия Федерациясе бюджет кодексының 93.2 статьясы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карарларына таянып, муниципаль район алдында акчалата йөкләмәләре буенча бурычлыларның бурычын җайга салу шартларын билгели торган, йөкләмәләр үтәүне кичектереп тору, йөкләмәләрне өлешләп үтәү турында, шулай ук бурычлыларны исәпләнгән пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләүдән тулысынча яисә өлешчә азат итү юлы белән йөкләмәләр күләмен киметү турында уртак килешүләр төзергә хокуклы.

**19 нчы статья**

Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми бастырылырга тиеш.

Рәис урынбасары З.Х. Сөнгатуллина